Хафизов, Р. "Тамашачының зәвыгы үсте" / Р. Хафизов; [әңгәмәдәш] Л. Сафина // Ватаным Татарстан. – 2023. – №2 (10 гыйнвар). – Б. 3.

## ЧАЛЛЫ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ТЕАТРЫ ДИРЕКТОРЫ РӘСИМ ХАФИЗОВ:

# «ТАМАШАЧЫНЫҢ ЗӘВЫГЫ ҮСТЕ»

Мәдәният

**Чаллы театры февральдә 3 көнлек гастрольләр белән Казанга килергә җыена. Башкала тамашачысы Чаллы тамашачысыннан нәрсәсе белән аерыла? Яңа бинага күчү театр тормышын ничек үзгәрткән? Халыкка нинди спектакльләр кирәк? Болар хакында Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының башкарма директоры Рәсим ХАФИЗОВ белән сөйләштек.**



**:: Рәсим Рәхимҗанович, Чаллы театры берничә ел эчендә шактый зур үзгәрешләр кичерде. Иң зурысы – яңа бинага күчү театр тормышын ничек үзгәртте?**

– Без әле дә зур үзгәрешләр юлында. Чаллыда яңа театр формалашып килә. Бина, репертуар, актерлар, тамашачы – барысы да үзгәрде. Кечкенә генә бинадан зур, зәвыклы, җиһазлау ягыннан матур бинага күчтек. Татар театрлары арасында иң яхшы биналарның берсе дип әйтсәм дә, ялгыш булмас. Әйе, театрның яңа урыны турында күп фикерләр булды. Кемдер шәһәрнең ерак җирендә урнашканы өчен сүкте, ә кемдер, киресенчә, ошатты. Минемчә, театр шәһәрнең иң яхшы урынында урнашкан. Безнең янәшәдә генә – Марат Бигишев исемендәге театраль парк. Анда тәүлек буе кеше йөри, яшьләр өчен спорт, балалар өчен уен мәйданчыклары бар. Парк белән театр бергәлектә эшли. Төрле бәйрәмнәр, театраль Сабантуйлар үткәрәбез. Безнең өчен идеаль урын бу. Без кайда гына булсак та, театрны, сәнгатьне яраткан кеше юлын табачак һәм киләчәк. Аллага шөкер, кеше йөри, тамашачыбыз көннән-көн арта.

**:: Репертуарыгыз кайсы якка үзгәрде?**

– Репертуар эчтәлек ягыннан да, техник яктан да үзгәрде. Кайбер спектакльләр элеккеге бинадан яңасына күчмәде. Бу төрле сәбәпләргә бәйле: әйтик, декорацияләрнең иске булуы, спектакльнең заман таләпләренә туры килеп бетмәве һәм башкалар. Театрыбызның сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов алып барган репертуар сәясәте әкренләп үзгәрә бара. Спектакльләрнең дә, тамашачының да зәвыгы үсте. Тирән эчтәлекле, татар халкының яшәеше, үсеше, көнкүреше турында спектакльләребез күбәйде.

**:: Ә тамашачы бу үзгәрешләрне ничек кабул итте?**

– Тамашачы хәзер бөтенләй икенче. Артистлар яңаргач, алар да яңарды. Кеше хәрәкәтләнгән, йөргән саен яшәрә, диләр. Без үзгәрәбез, шуның белән бергә тамашачы да үсә. Аларга зәвыклы, уйландыра, фикер йөртә торган спектакльләр кирәк. Безнең театрга татарлар гына түгел, руслар, татар телен белмәгән төрле милләт вәкилләре дә бик күп йөри. Узган ел шәһәргә Япониядән, Германиядән килгән кунаклар да безнең спектакльләрне карады.

**:: Театр яшьләр белән дә тыгыз элемтәдә. Әйтик, яңа бинада алар өчен «Яшьләр каурые» дигән коворкинг үзәге булдырылды.**

– Әйе, театрга килүче яшьләребез белән бик тыгыз аралашабыз, алар белән төрле чаралар үткәрәбез. Хәзер моның өчен театрыбызда бик матур һәм уңайлы коворкинг үзәге дә бар. Яшь рәссамнар, язучылар, фотографлар, блогерлар килә, үз идеяләрен тәкъдим итә. Театрыбызда «Театраль педагогика» дигән яңа проект та эшләп килә. Хәсән Туфан, Фатих Кәрим кебек язучыларыбызның биографияләре буенча «Хәл бу ки» спектакльләре чыкты. Ул күбрәк яшүсмерләр, мәктәп укучылары һәм укытучылары, студентлар өчен кызыклы. Мәктәптә язучыларның биографияләрен өйрәнәләр, ә театрга килеп, әйтик, Хәсән Туфанны, аның тормышын үз күзләрең белән күрү – ул бөтенләй икенче әйбер.

**:: Казанга кайсы спектакльләрегез белән киләсез? Гомумән, кеше иң яратып йөри торганнары нинди?**

– Казан тамашачысы алдында уйнау безнең өчен – зур сынау, имтихан ул. Гастрольләргә иң «кассовый» спектакльләрне алып киләбез. Ул да булса, классик Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр» җырлы-биюле спектакле. Анда бөтен труппа диярлек катнаша. Шулай ук халык бик яратып йөри торган «Капка» һәм «Болан» спектакльләре.

**:: «Шәһәр.Нокта.Брежнев» спектаклен әйтмәдегез. Ул ни өчен алдырып китә алмады? Үзегезнең шәһәр турында бит.**

– Алдырып китә алмады, дип әйтә алмыйм, аңа тамашачы йөри. Бу спектакльнең үзенчәлеге шунда: ул 3 сәгать 55 минут бара. Театр, гомумән, Чаллы өчен мондый тәҗрибә беренче тапкыр. Безнең тамашачы андый озын спектакльләргә ияләнмәгән әле.

**:: Бу сезонда тамашачыларны тагын нинди премьералар көтә?**

– Хәзер без чираттагы премьераны әзерлибез. Галиәсгар Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев бездә Антон Чеховның «Чайка» («Акчарлак») спектаклен куячак. Минемчә, бик кызыклы булачак. Тамашачылар инде: «Татар театрында Чеховны ничек күрсәтәсез?» – дип кызыксына башлады. Бу – алар өчен дә, безнең өчен дә үзенә күрә бер сынау. Әйтик, Казан тамашачысы өчен татар сәхнәсендә рус классигы әсәрен кую яңалык тудырмый, ул күпне күргән инде. Ә Чаллы тамашачысы өчен бу – зур яңалык, аны берникадәр селкетеп җибәрү.

Ләйсән САФИНА